СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«24» март 2023 ел** **№ 196**

**«Арча муниципаль районы бюджетыннан финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Арча район Советының 2020 елның 23 июнендәге 335 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 01 июнендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 30 гыйнварындагы 70 номерлы карары нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы бюджетыннан финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Арча район Советының 2020 елның 23 июнендәге 335 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Арча муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә:

«3.1.Грант акчаларын тоту рөхсәт ителгән чаралар исемлеге:

территорияне төзекләндерү (көнкүреш калдыкларын чыгару, утильләштерү һәм эшкәртү, кар җыю (чыгару), яшелләндерү, ишегалды территорияләрен һәм урамнарын яктырту);

шәфкатьлелек һәм хәйрия акцияләрен оештыру, мондый акцияләрне үткәрүдә җирле үзидарә органнарына, хәйрия фондларына, башка оешмаларга, гражданнар-

га һәм аларның берләшмәләренә (бинаны, автомобильләрне, автобусларны арендалау, азык-төлек продуктларын, медицина эшләнмәләрен, индивидуаль яклау чараларын, гигиена чараларын сатып алу, социаль ашханәләрне оештыру, халыкның социаль якланмаган катламнары, ятим балалар, инвалидлар өчен беренче кирәк-ярак сатып алу, хәйрия фондларына максатчан кертемнәр);

халыкның ял итү сыйфатын күтәрү (мәдәни, спорт һәм ял итү чараларын оештыру һәм уздыру);

торак хуҗалыгында җылылык, электр энергиясе, газ һәм су югалтуларын киметүгә юнәлдерелгән эшчәнлек;

ял итү урыннары территорияләрен, паркларны, скверларны төзекләндерү (коймалар, кече архитектура формалары, эскәмияләр, контейнерлар урнаштыру);

юл өслекләрен һәм тротуарларны ремонтлау;

балалар һәм спорт мәйданчыкларын урнаштыру, шул исәптән спорт инвентарен сатып алу (урнаштыру);

бәйрәм чараларын үткәрү (декорацияләр, бүләкләр сатып алу);

территориаль иҗтимагый үзидарәнең оештыру эшчәнлеге (гражданнарны кабул итү өчен оештыру техникасы, җиһазлар сатып алу, мәгълүмати стендлар әзерләү (сатып алу), канцтоварлар һәм хуҗалык инвентарьлары (көрәк, метл, бензопил, мотоблок, чапкыч) сатып алу;

видеокүзәтү системаларын сатып алу һәм урнаштыру;

территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләү.»;

2) 7 пунктта «Файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 пунктта:

өченче абзацта «Файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 пунктта «Файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Арча муниципаль районы бюджетыннан финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Арча район Советының 2020 елның 23 июнендәге 335 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү формасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk/tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Кушымта
Форма
Арча район Советының
_________2023 ел, №__
карары белән расланды

Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү

Арча шәһәре
"____" _____________ ел №___

Нигезләмә нигезендә эш итүче, аңа Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак җирлек бюджетларына башка бюджетара трансферт бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Арча муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән җитәкче __________________, киләчәктә "Башкарма комитет" дип аталачак, бер яктан, һәм, Устав нигезендә эш итүче авыл җирлекләре башкарма комитеты исеменнән _______________________, алга таба Вәкаләтле орган дип аталачак, икенче яктан, бергә Яклар дип аталачак, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «20___ елга һәм 20__ һәм 20__ еллар план чорына Арча муниципаль районы бюджеты турында» Арча муниципаль районы Советының ______________ ел, №__ карары, һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитетының _________________ ел, №__ күрсәтмәсе нигезендә Арча район Советының _____________________ ел, №__ карары белән расланган Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе (алга таба-бюджетара трансфертлар бирү тәртибе) турында әлеге Килешүне төзеделәр:

I. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып 20_____ елда Арча муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе кодлары буенча (Арча муниципаль районы бюджетының баш бүлүчесе коды 828, 01 бүлек, 13 бүлекчә, 995180 статья, 540 чыгымнар төре) "Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар бирү өчен башка бюджетара трансферт бирү тора.

II. Башка бюджетара трансферт бирүне финанс белән тәэмин итү

2.1. Башка бюджетара трансферт Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатка түбәндәге күләмдә бирелә:

20_____ елда________________________________________________________

III. Башка бюджетара трансферт бирү шартлары һәм тәртибе

**3.1.** Башка бюджетара трансферт «20___ елга һәм 20__ һәм 20__ еллар план чорына Арча муниципаль районы бюджеты турында» Арча муниципаль районы Советының ______________ ел, №__ карарында (Арча муниципаль районы бюджетының финанс елына һәм 20__- 20__ еллар план чорына җыелма бюджет бүленеше) каралган бюджет ассигнованиеләре

чикләрендә һәм Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә финанс елына бирелә.

3.2. Арча муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертны күчерү Вәкаләтле органның Федераль казначылык идарәсенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль органында җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган шәхси счетына Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән күләмдә әлеге Килешү төзелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.3. Вәкаләтле орган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грант бирүгә башка бюджетара трансферт тота.

## IV. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Башкарма комитет түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

4.1.1. Вәкаләтле органга Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертны бирүне тәэмин итәргә;

4.1.2. Вәкаләтле органның әлеге Килешүнең 3.2 пункты нигезендә күрсәтелгән счетына башка бюджетара трансфертны күчерүне тәэмин итәргә;

4.1.3. Вәкаләтле орган тарафыннан бирелә торган документларны тикшерергә;

4.1.4. Әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган әлеге Килешүгә 1 нче кушымта нигезендә башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенең мәгънәсен күрсәткечен билгеләргә;

4.1.5. Әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә әлеге Килешүгә 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча әлеге Килешүнең 4.3.3.3 пункты нигезендә тапшырылган башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисап нигезендә әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган форма буенча башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсен бәяләүне башкарырга;

4.1.6. Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Килешүдә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

4.1.7.Башкарма комитет яки муниципаль финанс контроле органы тарафыннан Вәкаләтле органның башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен һәм әлеге Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу фактлары ачыкланганда, шул исәптән әлеге Килешүгә ярашлы рәвештә Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар күрсәтелгәндә, Вәкаләтле органга башка бюджетара трансфертны Арча муниципаль районы бюджетына күрсәтелгән таләп белән билгеләнгән күләмдә һәм срокларда кире кайтаруны тәэмин итү турында таләп (алга таба – таләп) җибәрергә;

4.1.8. Әлеге Килешүнең 4.4.2 пункты нигезендә Вәкаләтле органнан мөрәҗәгать алынган көннән алып 10 эш көне эчендә әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча Вәкаләтле органга аңлатмалар җибәрергә;

4.1.9. Россия Федерациясе бюджет законнарында, башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

4.2. Башкарма комитет түбәндәгеләргә хокуклы:

4.2.1. Әлеге Килешүнең шартларын үзгәртү турында, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан җибәрелгән мәгълүмат һәм тәкъдимнәр нигезендә, башка бюджетара трансферт күләмен киметүне кертеп, карар кабул итәргә, шулай ук әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән файдаланылмаган бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда һәм Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге үзгәрешне финанс-икътисади нигезләүне үз эченә алган мәгълүмат алу шарты белән, башка бюджетара трансферт күләмен арттырырга;

4.2.2. 20_____ елда файдаланылмаган башка бюджетара трансферт калдыгын 20____

елга әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга юнәлтү ихтыяҗы булу турында һәм күрсәтелгән бюджетара трансферт калдыгын Вәкаләтле органга агымдагы финанс елындагы башка бюджетара трансферт калдыгыннан артмаган күләмдә күрсәтелгән максатларга кайтару турында Вәкаләтле органнан башка бюджетара трансферт калдыгына ихтыяҗны нигезли торган документлар алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча карар кабул итәргә;

4.2.3. Вәкаләтле органнан әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны соратып алырга.

4.2.4. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4.3. Вәкаләтле орган түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

4.3.1. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә;

4.3.2. Әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган Килешүгә 1 нче кушымтада билгеләнгән чараны гамәлгә ашыру кысаларында башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итәргә;

4.3.3. Башкарма комитетта әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында, раслаучы документларның күчермәләрен теркәп, һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган әлеге Килешүгә 3 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап тапшырырга;

4.3.4. әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән чарага башка бюджетара трансферт акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә;

4.3.5. Башкарма комитет үтенече буенча әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә башка бюджетара трансферт бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны күрсәтелгән запрос алынган көннән биш эш көне эчендә җибәрергә;

4.3.6. Башкарма комитет һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлеше буенча тикшерүләр үткәрүгә комачауламаска;

4.3.7. Башкарма комитеттан әлеге Килешүнең 4.1.7 пункты нигезендә таләп алынган очракта:

4.3.7.1. күрсәтелгән таләптә билгеләнгән срокларда башка бюджетара трансферт бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу фактын (ларын) бетерергә;

4.3.7.2. башка бюджетара трансфертны күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарырга;

4.3.7.3. Әлеге Килешү нигезендә Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итәргә;

4.3.8. башка бюджетара трансфертның хисап елыннан соң килүче финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмаган өлешен Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарырга;

4.3.9. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезендә башка йөкләмәләрне үтәргә.

4.4. Вәкаләтле орган түбәндәгеләргә хокуклы:

4.4.1. башка бюджетара трансферт күләмен үзгәртү зарурлыгы булган очракта, шул исәптән әлеге үзгәрешне финанс-икътисади нигезли торган мәгълүматны теркәп, Башкарма комитетка әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр җибәрергә;

4.4.2. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә аңлатмалар алу максатыннан Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә;

4.4.3. әлеге Килешүнең 4.2.2 пункты нигезендә тиешле башка бюджетара трансфертның калган өлеше Башкарма комитет тарафыннан кире кайтарылган очракта, әлеге Килешү ниге-

зендә алынган башка бюджетара трансфертның файдаланылмаган өлешен (булган очракта) әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга 20____ елда түләүләр башкаруга җибәрергә;

4.4.4. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. 3.Әлеге Килешү шартларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен яклар Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылыкка ия.

5.2. Вәкаләтле орган әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрнең теләсә кайсын бозган очракта, әлеге Килешүдә каралган документларны һәм хисапларны вакытында бирмәгән яисә вакытында бирмәгән очракта, әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән, дөрес булмаган белешмәләр биргән очракта, башкарма комитет әлеге Килешүне хәбәрнамәне алган көннән алып эш көннәрендә саналган 10 көн эчендә башка бюджетара трансферт акчаларын кире кайтаруны таләп итеп, әлеге Килешүне вакытыннан алда өзү юлы белән өзәргә хокуклы.

5.3. Хисап финанс елында кулланылмаган башка бюджетара трансферт акчалары булган очракта, калган акчалар хисап елыннан соң килә торган елның беренче 15 эш көне эчендә Арча муниципаль районы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

## VI. Контроль һәм хисаплылык

6.1. Вәкаләтле орган Башкарма комитетка тапшыра:

6.1.1. әлеге килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә әлеге килешүнең 1 нче кушымтасы нигезендә 20 _ елның 1 июленә кадәр башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап.

6.1.2. әлеге Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә әлеге Килешүнең 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештә 20___ елның 15 гыйнварына кадәр срокка башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап.

6.1.3. әлеге Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә, хисап чорыннан соң килүче айның 7 числосына кадәр квартал саен әлеге Килешүнең 4 нче кушымтасы нигезендә башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап.

6.1.4. Әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә башка бюджетара трансферт бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен Башкарма комитет сората торган мәгълүматны күрсәтелгән запрос алынган көннән соң биш эш көне тапшыра.

6.2. Башка бюджетара трансфертны максатчан куллануны тикшереп тору Башкарма комитет тарафыннан әлеге Килешүнең 6.1 пунктында күрсәтелгән хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## VII. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

7.1. Әлеге Килешү яклар кул куйганнан соң үз көченә керә һәм 20_ елның 1 июленә кадәр гамәлдә була.

7.2. Килешүнең гамәлдә булу вакытын туктату Вәкаләтле орган тарафыннан Килешүнең 4.3.3, 4.3.5, 6.1.1, 6.1.2 һәм 6.1.3 пунктлары нигезендә Башкарма комитетка хисап бирү буенча йөкләмәләрдән азат итми.

## VIII. Башка шартлар

8.1. Әлеге Килешүгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр алар тиешенчә язма рәвештә рәсмиләштерелгән һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракларда гына гамәлдә.

8.2. Әлеге Килешүне үтәү барышында барлыкка килергә мөмкин булган барлык бәхәсләр һәм каршылыклар Яклар тарафыннан сөйләшүләр һәм консультацияләр юлы белән хәл ителә.

8.3. Бәхәсләр сөйләшүләр һәм консультацияләр юлы белән хәл ителмәгән очракта, бәхәсләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә суд тарафыннан хәл ителергә тиеш.

8.4. Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия булган ике чын язма нөсхәдә төзелде, бер нөсхә Башкарма комитет өчен, икенчесе – Вәкаләтле орган өчен.

8.5. Башка бюджетара трансфертны алучы Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен, шулай ук әлеге Килешүне үтәүне тикшерүгә ризалык бирә.

## IX. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 12 й.<br>РОСИЯ БАНКЫ//УФК Татарстан Республикасы буенча филиалы<br>Бердәм казначылык счеты: 40102810445370000079<br>Керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казна счеты: 03100643000000011100<br>БИК 019205400<br>Алучы: УФК Татарстан Республикасы буенча (Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы)<br>л/с 04113000100<br>ИНН/КПП 1609009548/160901001<br>ОГРН 1061685000299<br>ОКТМО 92612000 | |

Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Арча муниципаль районы<br>Башкарма комитеты<br>___________/ | Вәкаләтле орган<br><br>___________/ |

Арча муниципаль районы бюджетыннан Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетларына территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә башка бюджетара трансферт бирү турында килешүгә 1 нче кушымта

Форма

Башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар түләүгә шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Арча муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирелүен раслыйм.

| ТҖҮ исеме | Вакыты, урыны, катнашучыларны күрсәтеп, чаралар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр исеме<br><br>(башкаручы) | Катнашучылар саны, кеше | чаралар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләрне раслый торган документларның исемнәре реквизитлары, раслый чаралар, эшләр яисә | Барлыгы, шул исәптән бюджеттан тыш акча, сум |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | Барлыгы: |

Хисапка әлеге хисап мәгълүматларын раслый торган документларның тиешенчә расланган күчермәләре һәм фотоматериаллар теркәлә.

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

ФИАИ: _________ Имза_____________________________

Дата «____» _________________ел

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе

ФИАИ: _________ Имза_____________________________

Дата «____» _________________ел

Арча муниципаль районының ТҖҮ җитәкчесе

| № т/б | ТҖҮ исеме | ФИАи | Имза | Датасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Арча муниципаль районы бюджетыннан
Арча муниципаль районы жирлекләре бюджетларына территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә башка бюджетара трансферт бирү турында килешүгә 2 нче кушымта

Бюджетара башка трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткече

| Чара исеме | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге ОКЕИ буенча | | Планлаштырылган күрсәткеч | Күрсәткечкә ирешүнең планлаштырылган срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Исеме | Коды | | |
| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерү | Конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга түләнгән грантлар саны | үлчәү берәмлеге | 642 | | 31.12.20__ |

Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

_____________/

Вәкаләтле орган:

_____________/

Арча муниципаль районы бюджетыннан
Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетларына территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә башка бюджетара трансферт бирү турында килешүгә 3 нче кушымта

20____ елга
башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап

Алучының исеме_________________________________________
ешлыгы: еллык

| № т/б | Чара исеме | Күрсәткеч исеме | Планлаштырылган күрсәткеч | Хисап датасына ирешелгән күрсәткечләр торышы | Планны үтәү проценты | Планны үтәмәү сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Хисап кабул ителде:

Алучының җитәкчесе
(вәкаләтле зат)

__________________________________ ___________________
*(вазыйфа, имза, имзаны аңлату)* *имза*

Башкаручы _____________________
*(вазыйфасы, ФИАи, телефон)*
«___» _____________ 20 ___ел

____________________________
*(имза)*
"____" ______ ________ел

Арча районы Башкарма комитеты җитәкчесе Алучы:

_____________/___________/ _____________/ ________________/

Арча муниципаль районы бюджетыннан Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетларына территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә башка бюджетара трансферт бирү турында килешүгә 4 нче кушымта

Форма

Башка бюджетара трансфертны куллану турында хисап

« » 20 _ ел

Вәкаләтле орган исеме ________________________________________

ешлыгы: квартал

Үлчәү берәмлеге: сум (икенче унлы билгегә кадәр)

| Күрсәткеч исеме | Суммасы | | Чыгымнарны раслый торган документлар реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Ел башыннан үсә барган нәтиҗә белән | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Агымдагы финанс елы башына башка бюджетара трансферт калдыгы, барлыгы | | | |
| шул исәптән: расланган ихтыяҗ | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиешле | | | |
| Башка бюджетара трансферт чаралары, барлыгы | | | |
| Хисап датасына касса чыгымнары, барлыгы | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар, барлыгы | | | |
| шул исәптән: максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына барлыгы кире кайтарылды | | | |
| шул исәптән: агымдагы финанс елы башына Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча калдыгы | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле акчалар | | | |
| шулардан: максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Хисап чоры ахырына башка бюджетара трансферт калдыгы, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>Арча муниципаль районы бюджеты кире кайтарылырга тиеш | | | |

Хисапка күрсәтелгән таблицаның 4 нче графасында санап үтелгән чыгымнарны раслый торган документларның тиешенчә расланган күчермәләре теркәлә.

Вәкаләтле орган ________________ _________ __________________________

(вазыйфасы) (имза) (имзаны аңлату)

Башкаручы ________________ ________________ _______________

(вазыйфасы) (Ф. и. а.и.) (телефон)

"___" __________ 20__ ел

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

_____________/

Вәкаләтле орган:

_____________/